Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенең Өтернәс торак пунктында

ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

09.11.2019 № 1

06.10.2003 елның № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 елның 29 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенең Өтернәс торак пункты территориясендә халык җыены карар итте:

1. 2020 нче елда Саба муниципаль районының Эзмә авыл җирлегенең Өтернәс торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшне башкаруга юнәлдерергә:

- Өтернәс авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/izma адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

Халык җыенында<br>
рәислек итүче,Эзмә авыл<br>
җирлеге башлыгы А.Р.Шәйхетдинов